**“Тау ягы “VI Төбәкара конференция**

Үзәкләргә үткән сугыш...

( Бөек Ватан сугышы елларында Яшел Үзән шәһәре )

**Эшне башкарды:**
**Яшел Үзән шәһәре**
**А.С. Пушкин исемендәге 9 нчы лицейның**
**11 сыйныф укучысы**
**Газизова Эльмира Илдар кызы**
**Җитәкче: Биккиннина Динә Абдулла кызы**

**2020 нче ел**

**Эчтәлек**

**Кереш.**

**Төп өлеш.**

1. **Лицейның Бөек Ватан сугышы музее.**

2. **Сугыш елларында Яшел Үзән.**

3. **Тылда – фронттагы кебек!**

4. **Станоклар да хәтта чыдамаган.**

**Йомгаклау.**

**Файдаланылган әдәбият.**

**Кушымта.**

## Кереш

Хәтер...

Бары тик кешеләргә генә хас изге нәрсә. Ул безнең аңда мәңге яши. Яшәп кенә калмый, ә яңадан – яңа буын кешеләрен батырлыкларга өнди, хәзерге гамәлләрне элекке каһарманлыкларга тиңләргә чакыра.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм канкойгыч 1418 көне һәм төне кешелек хәтереннән мәңге чыкмас. Бу көрәштә илебезнең миллионлаган намуслы һәм батыр ул – кызлары җирдә тынычлык һәм бәхет өчен гомерләрен бирделәр, шуның аркылы алар үлемсезлеккә атлады. Аларның батырлыклары бүген дә яши һәм мәңге яшәячәк.  Шәһәр һәм авыллардагы мемориаллар һәм һәйкәлләр, сугышчан һәм хезмәт даны музейлары, Ватанны күкрәкләре белән каплаган гади совет сугышчыларының һәм тыл хезмәтчәннәренең илгә мәхәббәтен, фидакарьлеген, кыюлыгын чагылдырган китаплар, кинофильм һәм спектакльләр нәкъ менә шул турыда сөйли.

Бөек Ватан сугышы соңгы бәрелешләренең гөрелтесе елдан – ел ерагая бара, ләкин бүгенге тыныч таңнар өчен кем алдында бурычлы булуыбыз һәркайчан безнең хәтеребездә булырга тиеш. Ул еллар афәте турында махсус кинохроникалар һәм ветераннар сөйләве буенча гына белсәк тә, җиңүгә өлеш керткән якташларыбыз турында онытырга безнең хакыбыз юк.

Ул дәһшәтле көннәрдә Яшел Үзәнлеләр ил белән бергә көрәшкә күтәрелделәр һәм Бөек Ватан сугышының бөтен фронтларында да үзләрен чын каһарманнар итеп күрсәттеләр. Беренче көннәрдә үк райондашларыбыз хәрби эшелоннар белән фронтка юнәлде. Сугышның беренче ике атнасы эчендә завод цехлары ярым бушап калдылар. 34679 якташыбыз Бөек Ватан сугышы кырларында илебезне дошманнан яклады, аларның 17695енә әйләнеп кайту насыйп булмады. Ул көннәрдән ерагая барган саен, Җиңү шаһитлары арабызда сирәгәя бара. Аларның исемнәрен искә алганда күңелләрне сагыш катнаш горурлык хисе били. Без яу кырларында башларын салганнарга да, илебезгә

җиңү алып кайткан батырларга да, тылда армый – талмый эшләгәннәргә дә баш иеп рәхмәтебезне белдерәбез.

Бу эшкә алынуымның **максаты** – сугыш хатирәләре, туган җиребезне, туган илебезне илбасарлардан саклап калган, аның иминлеге өчен көчләрен дә, гомерләрен дә кызганмаган каһарманнарны хөрмәт һәм ихтирам белән искә алу, тынычлыкның кадерен аңларга тырышу.

Мин үз алдыма түбәндәге **бурычларны** куйдым:

1. Сугыш турындагы истәлекләрне өйрәнү.

2. Сугыш елларында шәһәребез кешеләренең Җиңүгә керткән өлешен ачыклау.

3. Сугышның нинди куркыныч, кешелек тарихында мәңге төзәлмәслек яра булуын исбатлау, тынычлыкның кадерен аңларга тырышу.

## Төп өлеш

### 1. Лицейның Бөек Ватан сугышы музее

Бу хезмәтемдә телгә алынган хәлләр, мисал – фактлар безнең лицейда 1997 елдан бирле эшләп килүче Бөек Ватан сугышына багышланган музей материалларында һәм экспонатларында төгәл чагылыш тапкан.

Тарих укытучысы Садриев Әхәт Шәйхи улы безгә эшкә килгәч, мәктәбебез укытучылары һәм укучылары белән берлектә Жуковка багышланган музейны оештыру эшенә керешә. Ләкин бу бөек шәхеснең исеме Бөек Ватан сугышы белән бик тыгыз бәйләнгәнлектән, Жуков музее тиздән 1941 – 1945нче еллардагы Бөек Ватан сугышы музеена әверелә. Хәзерге көндә тупланган 1500дән артык экспонатның күбесе ул дәһшәтле көннәр белән турыдан – туры бәйле: я каты сугышлар барган урыннардан табылган, я ул чордагы тыл тормышына кагылышлы. Һәр табылдык кемгәдер хезмәт иткән, кемнеңдер кул җылысын саклый кебек.

Күп еллар дәвамында музей каршында эшләп килгән эзләнү төркеме Россиянең төрле өлкәләреннән килгән башка эзтабарлар белән берлектә, сугыш юллары буйлап экспедицияләрдә булып, хәбәрсез югалганнарны эзләп табуда катнаштылар. Новгород өлкәсендә алып барган эзләнүләр нәтиҗәсендә, Мясной Бор авылы янында Яшел Үзән районының Татар Наратлысы авылыннан сугышка киткән һәм хәбәрсез югалган Касыймов Сәлим Касыйм улының медальонын таптылар, аның балаларына хәбәр иттеләр. Ватаныбыз азатлыгы өчен башын салган Сәлим аганың җәсәде туганнар каберлегендә җиргә иңдерелде, ә балалары җаннарына тынычлык тапты. Шунысы кызыклы, Сәлим ага безнең лицейның татар теле укытучысы Рушания Вәкиловнаның бабасы булып чыкты. Шушындый эзләнүләрдән музей фонды яңадан – яңа экспонатларга байый барды: сапер көрәкләре, солдат флягалары, медальоннар, гильзалар, мина һәм снаряд кисәкләре, зажигалкалар, солдат итегенең аерым өлешләре һәм башкалар.

Музей каршында “Патриот” клубы эшләп килә. Укучыларыбыз фәнни – тикшеренү эшләре белән кызыксынып шөгыльләнәләр. Лицейда ел саен Жуков укулары уза. Әлеге укуларда укучылар “Ватаным бүләкләре” , “Халкыбыз батырлары”, “Сугыш чоры балалары”, “Минем гаиләм һәм сугыш”,“Тыл хезмәтчәннәре”, “Сугыш чорында Яшел Үзәнлеләр” һәм башка шундый темаларга чыгышлар ясыйлар. Биредә “Буыннар очрашуы” даими оештырыла. Сугыш һәм тыл ветераннары бездә еш кунак була. Алар үзләренең кызыклы истәлекләре белән уртаклашалар. Еш кына берәр истәлек тә калдырып китәләр. Сугыш чорына кагылышлы савыт – саба, лампа, киемнәр, хатлар, радио һәм башкалар хисабына музей фонды тулылана бара. Стендлар, экспозицияләр, экспонатлар укучыларда, музейга килүчеләрдә зур кызыксыну уята. Магадан, Омск, Екатеринбург, Самара, Мәскәү, Санкт – Петербург... Америка, Италия, Финляндия вәкилләренең дә булганнары бар бездә. Музейда 40 меңгә якын кеше булган. Истәлекләр альбомында аларның фикерләре, музей эшенә биргән уңай бәяләре саклана.

Без лицеебызда шундый музеебыз булу белән бик горурланабыз. Күп еллар буе аның алыштыргысыз җитәкчесе булган Садриев Әхәт Шәйхи улына олы рәхмәтебезне һәм тирән ихтирамыбызны белдерәбез.

## 2. Сугыш елларында Яшел Үзән

1941 – 1945 елларда Яшел Үзән районы,бөтен ил кебек үк, сугыш чоры кануннары буенча яши. Кыска вакыт эчендә предприятиеләр хәрби продукция чыгара башлау өчен җайлаштырылалар. Сугышның беренче көннәрендә үк Серго исемендәге заводтан 227 кеше фронтка китә. Аннары бу сан 1200дән артып китә. 1941нче елның 7ноябренда Мәскәүдә Кызыл мәйданда булган парадта Серго исемендәге заводтан комсомол юлламасы белән сугышка киткән дүрт кеше – А.Ильин, М.Шәмсетдинов, П.Никулин һәм Ф.Сорокин да катнаша ( “Мәгариф” ж-лы, 2011 ел, № 12, 46 бит).Фронтка китүчеләрнең урыннарына эшкә аларның гаилә членнары – хатыннары, әтиләре, әниләре һәм уллары – кызлары килә. Әле тәҗрибәләре дә булмаган бу кешеләр һәм яшүсмерләр җилкәсенә сугыш чорының бөтен авырлыгы төшә.

И.Сталинның 3нче июльдә ясаган чыгышыннан соң шәһәр предприятиеләрендә хезмәт коллективларының митинглары булып уза. Аларда эшчеләр бер көнлек хезмәт хакын илне саклау фондына күчерү турында карар кабул итәләр. 1941елның 3июль санында “Зеленодольский рабочий” газетасы болай яза: “Фанера заводы директоры өстәлендә гаризалар ята. Анда бер генә үтенеч язылган: “Дошманны җиңү өчен бер көнлек хезмәт хакымны илебезнең оборона фондына күчерүегезне сорыйм”. Сугышның өч ярым елы эчендә Яшел Үзәнлеләр илне саклау фондына 30 миллион сумнан артык акча җыйнап тапшыралар. Бу акча “Татарстан комсомолы” танк колоннасы һәм “Яшел Үзән комсомолы” дип язылган самолет төзүгә тотыла. Яшел Үзән халкы броняланган, тулысынча коралландырылган 2 кораб төзү өчен акча бирә, һөнәр һәм тимер юл училищелары, ФЗУ мәктәпләре укучылары һәм хезмәткәрләре үз акчаларына һәм якшәмбе өмәләрендә эшләп тапкан акчага “Татарстан хезмәт резервлары” дигән торпеда катеры сатып ала. Катер Кара диңгез флотына кабул ителә.

Шәһәр һәм район мәктәпләрендә укучы балалар һәм укытучылар тарафыннан сугыш елларында фронтка 4 мең данә матур әдәбият,13 мең данә тәмәке янчыгы, 8500 посылка озатыла; 18 мең тонна металлолом җыеп тапшырыла, күпләп дару үләннәре җыела ( В.А.Федотов. Память… 158 бит).

1943елның 8 маенда Яшел Үзән районыннан Сталинградка күп санлы савыт – саба, урын – җир кирәк яраклары, китаплар, җиһазлар һәм терлек җибәрелә. Шул ук көнне ярты вагон лампа пыяласы, 4вагон шпал чималы, 10 вагон төзү материаллары да озатыла(шунда ук).

Сугыш елларында якташларыбызга кыюлык, фидакарьлек, ихтыяр көченнән тыш, шәфкатьлелек һәм мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар да хас була. Сугыш адыннан Яшел Үзән шәһәрендә 30 меңнән артык кеше исәпләнсә, 1941 елның ноябрь аена шәһәрдә кеше саны 60 меңгә җитә. Шәһәребездә эвакуация белән килгәннәрне сыендырмаган бер гаилә дә калмый. Үз әти – әниләрен, туганнарын югалткан илледән артык сабый Яшел Үзән гаиләләрендә кабат игътибар – тәрбия, җылылык – наз табалар.

Тормыш авырлашканнан – авырлаша бара. 1942 елның 2 октябренда шәһәр башкарма комитеты электр энергиясен экономияләү турында карар чыгара. Түбәндәге норма кертелә: 15 кв. метрлы бүлмәләрдә 15ВТ егәрлекле бер лампочка, 30 кв. метрда 25 ВТлы, башка урыннарда 15 ВТлы лампочкалар гына яндырырга ярый. Шәһәр урамнары инде сугыш башланганнан бирле бөтенләй яктыртылмый, чөнки 1941 елның көзендә немец авиациясе Казан тимер юлын бомбага тота, Яшел Үзән янындагы Идел күперен юк итәргә маташа. Шуңа күрә ут яктысын тулысынча яшерү режимы кертелә (Федотов В. А. Память сердца. Зеленодольск.2000).

Бигрәк тә ачлык үзен сиздерә.1942 елның 1 январеннан бөтен илдәге кебек азык – төлеккә карточка системасы кертелә. 1943 ел башында хәл тагын да кискенләшә. Җәй айларында шәһәр урамнарында яшелчә түтәлләре барлыкка килә. Эшчеләргә бирелә торган паек 12-15 сәгать эшләрлек көч бирә алмый. Аеруча эвакуация белән килүчеләрнең хәле авыр була. 1942 елның 10 январь карары белән аларга акчалата ярдәм күрсәтелә: 50 сумнан 300 сумга кадәр. Бу

акчага нәрсә алып булган соң? 1942 елда бер бөтен кара ипинең бәясе базарда 500 сумга кадәр җиткән ( Федотов В.А. Память сердца. 2000). 1944 елның 23 март карары белән аеруча мохтаж 39 гаиләгә 6шар килограмм бодай оны бирелә. Шул елда базардагы азык – төлек бәяләре болай була: бер бөтен ипи – 100 – 120 сум, 1 литр сөт – 10 сум, 1 кг бәрәңге – 10 сум, атланмайның бер кадагы – 50 сум, 1 стакан он – 7 сум, ит бөтенләй сатылмаган (шунда ук).

1941 елның июле уртасында 1нче һәм 2нче мәктәп биналарында 400 урынга исәпләнгән госпиталь оештыру, 8нче мәктәп бинасында яралыларны ашату өчен кухня ачу турында карар кабул ителә. Анда 1942 елда 6төр белгечлек буенча 63 табиб һәм шәкать туташы хезмәт итә, даими рәвештә 450 – 550 яралы сугышчы дәвалана, аякка баса (Федотов В. А. Патриот. Казан, 2012. 86бит).

### 3. Тылда - фронттагы кебек!

Якташларыбыз – меңнәрчә хезмәт кешесе шушы девизга турылыклы булып калды. Фронтка киткән кешеләрне производствода хатын – кызлар, яшүсмерләр, өлкән яшьтәге кешеләр алыштыра. Сугышның беренче атналарында ук “Үзең һәм фронтка киткән иптәшең өчен” дигән чакыруга кушылып, ике һәм өч кеше урынына эшләү массакүләм күренеш ала.
Сугыш башлану белән унбиш предприятиенең уникесе фронт өчен эшли башлый.

Сугыш чорында Яшел Үзән каласының Горький исемендәге суднолар төзү заводы фронт өчен барлыгы 162 судно, шул исәптән 121 бронекатер, 17 буксир, 5 баржа, 17 данә төрле корабльләр эшләп чыгара. Болардан тыш, 4 миллион 221 мең данә 76 миллиметрлы артиллерия снаряды, 2776 пулемет, 2760 авиабомба корпусы, 605 зенит җайланмасы, 25708 сапер көрәге, аэрочана детальләре һәм чуеннан, корычтан, бронзадан күп санлы эшләнмәләр җитештерә. Завод эшчеләре берничә мәртәбә хәрби моряклардан рәхмәт хатлары алалар. Бу исә аларны яңадан – яңа хезмәт батырлыкларына рухландыра.

Һәр ай саен Серго исемендәге завод 1миллион 500 мең снаряд җитештереп, фронтка барлыгы 62 миллионнан артык снаряд җибәрә! Горький һәм Серго

исемендәге заводлар, Яшел Үзән хезмәтчәннәре сугыш барышында СССРда эшләнгән һәр 10 снарядның берсен җитештерә, ягъни 70 миллионга якын снаряд фронтка озатыла ( “Мәгариф” ж – лы,2010 ел, № 3, 48бит ).1941 елның ноябренда Серго заводында тегү цехы эшли башлый. Аның җитәкчесе М.М.Большаков була. Комсомол – яшьләрдән генә торган бу цехта 200ләп кеше хезмәт итә. Алар өч сменада ял көннәрсез сугышчылар өчен бүрекләр, сырган чалбарлар һәм фуфайкалар, җылы эчке киемнәр, махсус бияләйләр тегәләр. Һәр ай саен транспорт самолеты әзер киемнәрне фронтка алып киткән. Яшел Үзәнлеләр теккән җылы киемнәр белән ике армияне тулысынча киендергәннәр(Федотов В.А. Память сердца. Зеленодольск, 2000. 159 бит).

Идел буе фанера һәм Яшел Үзән фанера заводлары югары сыйфатлы авиация фанерасы эшләп чыгарган. Шәһәр промкомбинаты Кызыл Армияне чаңгылар, маскахалатлар, юл капчыклары белән тәэмин иткән, “Большевик” артеле хром офицерлар итекләре, тегү остаханәләре солдат киемнәре теккән.

### 4. **Станоклар да хәтта чыдамаган**

Тылда сугышның бөтен авырлыгы хатын – кызлар, яшүсмерләр һәм картлар җилкәсенә төшкәнен һәркем белә. Музейда лицей укучыларының туганнары турында язып алынган истәлекләр саклана. Менә шуларның берсе - Сәйфетдинова Нурлыбану апа бу ачы хәсрәтле көннәрне үз башыннан кичерүе турында. Чүпрәле районының Иске Кәкерле авылында туып үскән кыз 1938 елда Яшел Үзән шәһәрендә урнашкан ФЗУ га укырга керә. Ике елдан слесарь һөнәре алып, Горький исемендәге заводның 17нче цехына эшкә килә. Матур гына эшләп йөргәндә, коточкыч хәбәр – сугыш башлануын ишетә. Һәр эшче кулы алтын бәясенә торырлык көннәр килә. Моны яхшы аңлаган 17 яшьлек кыз кыру(токарный) станогында эшләргә рөхсәт сорый. Нурлыбану апа сөйләвенчә, ул артиллерия снарядлары эшләүдә беренче вазифаны (операцияне) башкарган. Станокта үтә куәтле “Катюша”лар өчен 17 килограмм авырлыктагы снаряд эшләнмәләрен кырып эшкәрткән. Бер сменага 480 снаряд эшләргә кирәк булган, ә смена 14 – 15 сәгатькә сузылган. Ул елларда болай җырлаганнар:

Тәгәрмәчләр әйләнәләр,-

Ашыктырып һәрбер минутта.

Безнең заводларның ярдәм көчен

Җиткерергә тизрәк фронтка...

“Авыр хезмәт күп көч сорый, җитмәсә, ашау ягы да такы – токы, бик тиз арый идек. Һәр эшчегә азык – төлек карточкалары һәм 600 грамм икмәк бирәләр иде,- дип искә алган Нурлыбану апа.

Бертуктаусыз эшләтүгә хәтта станоклар да чыдамаган. Бервакыт шундый хәл була. Нурлыбану апа станокта резец дип аталган детальне кыра икән. Минутына 500 әйләнеш ясый торган кыру тәгәрмәче кинәт ярылып, югарыга оча. Ә “коржик” дип атала торган деталь кызның башына килеп бәрелә. Аны хастаханәгә озаталар. Озак кына дәваланып, яңадан үзенең эш урынына кайта ул.

Башка бик күпләр кебек, Нурлыбануның фронтка китәсе килгән. Ул хәрби шоферлар әзерли торган өч айлык курсларны тәмамлый. Көн саен чакыру көтә. Ләкин авыр хезмәт нәтиҗәсеме, ачлы – туклы яшәүдәнме, үпкәсе чирләп киткәч, аны армиягә яраксыз дип табалар. Ул заводта эшләвен дәвам итә.

Сугыш елларындагы тырыш хезмәте өчен Нурлыбану апа Сәйфетдинова медальләр һәм Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Нурлыбану апаның тормышы акрынлап җайга салына: савыгып, яраткан кешесе белән гаилә кора, өч ул тәрбияләп үстерәләр, оныкларын тәрбияләргә ярдәм итәләр. Сугышның фаҗигале хатирәләре аның күңеленнән беркайчан да китми. Бер очрашу вакытында ул үзенең истәлекләрен түбәндәге юллар белән тәмамлаган иде:

Тынычлыкны саклыйк, тынычлыкны,
Кабынмасын сугыш утлары!
Авылларны, калаларны җимереп,
Шартламасын дошман туплары!

## Йомгаклау

Вакыт тәгәрмәче әйләнәнүен дәвам итә... Бөек Ватан сугышы тәмамлануга быел 75 ел була. Утлы еллар вакыйгалары бездән көннән – көн ерагая бара. Ул дәһшәтле көннәрнең шаһиты булган кешеләрнең дә сафлары сирәгәйгәннән – сирәгәя. Бүгенге көндә исән булганнарның , ятим калган, яшьтән ятим үскән сугыш чоры балаларының да күңелләре мәңге әрнүле, китек килеш кала бирә. Алар күңелендә сугыш калдырган яра беркайчан  төзәләсе түгел. Бу сугыш бөтен халык сугышы булды, чөнки Ватанны саклауга бөтен кеше: карты да, яше дә, ирләр һәм хатын – кызлар, бөек илебезнең барлык милләтләре күтәрелде. Сугыш кырларында моңарчы күрелмәгән ныклык һәм героизм, тылда тәүлек буе диярлек армый – талмый хезмәт итү – менә нәрсә иде бу сугыш.

Без халкыбызның менә шул батырлык һәм фидакарьлекләрен, зур югалту һәм корбаннарын һич кенә дә истән чыгармаска тиешбез. Шул вакытта гына дөньяда иминлек һәм тигезлеккә омтылу, үзара дустанә мөнәсәбәтләргә омтылу көчлерәк, куәтлерәк булыр. Бер кичергән афәт, газаплар икенче шундый кичерешләрдән кисәтеп кала алсын иде. Без, үсеп килүче яшь буын, халкыбызның батырлыгы турында сүнмәс - тоныкланмас хатирә итеп, буыннан – буынга тапшырырга сүз бирәбез.

Бу хезмәт тә шуны искәртеп тору өчен язылды.

**Файдаланылган әдәбият:**

1. Гыйлманов Җ. Без сугышта юлбарыстан көчлебез. Казан, 1989.

2. Казанские ведомости №26 , 26 февраль, 2015 ел.

3. «Мәгариф» журналы, № 3, 2010 ел.

4. «Мәгариф» журналы, № 12, 2011 ел.

5. «Мәгариф» журналы, № 1, 2013 ел.

6. "Музей Великой Отечественной войны 1941 – 1945 годов лицея №9" җыентыгы, Яшел Үзән, 2007.

7. Федотов В.А. Память сердца ( война в судьбах зеленодольцев ). Зеленодольск, 2000.

8. Федотов В.А. Патриот. Казань, 2012.

**Кушымта**












***Музей экспонатлары***





Яшел Үзән заводларына эшкә шундый яшүсмерләр килә



*Нурлыбаян апа Сәйфетдинова оныгы белән*

**«Тынычлыкның кадерен белегез, улым!»**